**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_______________ № ________

**Тәтеш муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының штат расписаниесенә «балалар иҗтимагый берләшмәләре белән тәрбия һәм хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесе»вазыйфасын кертү турында**

«Россия Федерациясендә гражданнарны патриотик тәрбияләү» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында «2024 елның 1 гыйнварыннан балалар иҗтимагый берләшмәләре белән тәрбия һәм хезмәттәшлек буенча директор киңәшчеләре ставкаларын кертү буенча Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының исемлеген раслау турында» 19.12.2023 № 2287/23 Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы нигезендә Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты карар кылды:

1. Тәтеш муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының штат расписаниесенә «балалар иҗтимагый берләшмәләре белән тәрбия һәм хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесе» вазыйфасын кертергә (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Н.В.Николаевага йөкләргә.

**Җитәкче** **А.А. Гасыймов**